ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.06.2025 Балык Бистәсе штп. № 147пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 27 маендагы «Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетларының үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләренә һәм белгечләренә, баш бухгалтерларга һәм бухгалтерларга (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан гайре) хезмәт өчен түләүне оештыру һәм түләү шартлары турында»гы 181пи номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Шәһәр һәм авыл җирлекләре үзәкләштерелгән бухгалтерияләре җитәкчеләренә һәм белгечләренә, бухгалтерларына хезмәт хакы түләү турында» 2025 елның 3 апрелендәге 03-12/2212 номерлы хаты нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 27 маендагы «Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетларының үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләренә һәм белгечләренә, баш бухгалтерларга һәм бухгалтерларга (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан гайре) хезмәт өчен түләүне оештыру һәм түләү шартлары турында»гы 181пи номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-хуҗалык бүлекләре җитәкчеләренә һәм белгечләренә хезмәт өчен түләүне оештыру һәм түдәү шартлары турында Нигезләмәнең 3 пунктында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-хуҗалык бүлекләре җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи айлык хезмәт хакларын яңа редакциядә бәян итәргә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфалары | Вазыйфаи айлык хезмәт хакы, сумнарда | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Башкарма комитетның (җирле үзидарәнең башка органының) структур бүлекчәсе (бүлеге) булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 37 000 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 34 600 | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтер) | | 34 600 |
| Бүлек башлыгы | 30 500 | 30 500 |
| Әйдәүче бухгалтер | 27 800 | 27 800 |
| Бухгалтер | 26 400 | 26 400 |

1.2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль берәмлекләре Башкарма комитетларының баш бухгалтерларына һәм бухгалтерларына хезмәт өчен түләүне оештыру һәм түләү шартлары турында Нигезләмәнең 3 пунктында бухгалтерларның (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан гайре) вазыйфаи айлык хезмәт хакларын яңа редакциядә бәян итәргә:

| Вазыйфа | Халык саны түбәндәгечә булган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары | |
|---|---|---|
| | 3,5 мең кешегә кадәр | 3,5 мең кешедән артык |
| Баш бухгалтер | 28 200 сум | 29 700 сум |
| Бухгалтер | - | 27 000 сум |

2. Хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычлары күләме сакланып калганда һәм шул ук квалификациядәге эшләр башкарганда, хезмәткәрләрнең хезмәт хакының әлеге карар нигезендә билгеләнә торган күләме 2025 елның 30 апреленә түләнә торган хезмәт хакы күләменнән ким була алмый.

3. Карарның көче 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе И.М. Ногмановага йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сатдинов